Казан (Идел буе) федераль университеты газетасы

# DARELFӨNYN
УНИВЕРСИТЕТ

№26 (39)

27 сентябрь 2012 ел

## • Универ хәлләре

24 сентябрь көнне ректорат утырышы башында **РЕКТОР ИЛШАТ ГАФУРОВ** җәй көне Лондонда уздырылган җәйге олимпия уеннарында алтын медаль яулаган университетыбыз студентлары **ЮЛИЯ ЗАРИПОВА, АЛЕКСЕЙ ОБМАЧАЕВ, ОСТАЗЛАРЫ ЭДУАРД МОЖАЕВ, СЕРГЕЙ ПАВЛОВНЫ** котлады. Аларга бүләкләр тапшырылды. Моңа өстәп Юлия Зариповага КФУ дипломын да бирделәр.

• • • •

Ректорат утырышы да тантаналы рухта узды. Социаль һәм тәрбия эшчәнлеге буенча проректор **АРИФ МЕЖВЕДИЛОВ** Татарстан Студентлары хезмәт отрядларының II Спартакиадасында **КФУ КОМАНДАСЫНЫҢ БЕРЕНЧЕ УРЫН ЯУЛАВЫН, УНИВЕРСИАДА АВЫЛЫ СТУДЕНТЛАР АССОЦИАЦИЯСЕ «СТУДЕНТЛАР АКТИВЫ 2012» БӨТЕНРОССИЯ КОНКУРСЫНЫҢ ЛАУРЕАТЫ БУЛГАНЫН БИЛГЕЛӘП ҮТТЕ**. Икътисад һәм финанс институты студенты Рөстәм Кыямов математикага багышланган студентлар өчен ачык халыкара Интернет-олимпиадасы (ОIIО – Open International Internet-Olympiad) суперфиналында катнашып, беренче дәрәҗәдәге диплом белән бүләкләнгән. Шул ук институтта белем алган Рәсимә Икасова «Россия югары уку йортларының финанс-икътисад факультетларын тәмамлаучылар арасында иң яхшы диплом эше – 2012» дип исемләнгән Россиякүләм конкурста җиңүче булган.

Мактау сүзләреннән соң, Илшат Гафуров үзенең «Сочи-2012» XI халыкара инвестицион форумында катнашканы турында сөйләде. Җитәкче шулай ук Перспектив үсеш үзәге директоры вазифасына Савеличев Михаил Валерьевичны тәкъдим итте. Укыту-методик идарәсе башлыгы Ольга Тимофеева КФУдагы төп мәгариф программалары турында бәян итте. Мәгариф Департаменты директоры Галина Ившина КФУда электрон мәгариф ресурсларын булдыру һәм алардан куллану турында мәгълүмат бирде.

«Төрле мәсьәләләр» өлешендә Мәгълүматлаштыру һәм элемтә департаменты башлыгы Дмитрий Бурмистров лингафон җиһазларны урнаштыру һәм мультимедияле аудиторияләрнең кулланылуы турында статистика белән таныштырды. Алга таба юридик факультетның конституцион хокук һәм кеше хокукы кафедрасы исемен конституцион һәм административ хокук кафедрасына алыштырырга, Идарә итү һәм территориаль үсеш институтында табигатьне җайга салу һәм су кулланылышы кафедрасын булдыру турында карар кабул ителде.

• • • •

20-23 сентябрь көннәрендә ТР делегация составында КФУ ректоры **ИЛШАТ ГАФУРОВ** белән икътисади һәм стратегик үсеш буенча проректор **МАРАТ САФИУЛЛИН «СОЧИ-2012» XI ХАЛЫКАРА ИНВЕСТИЦИОН ФОРУМЫНА БАРЫП КАЙТТЫ**. Илшат Гафуров РФ мәгариф системасы һәм университетлар темасына багышланган «түгәрәк өстәл»дә катнашып, берничә очрашуда, шул исәптән, Россиядәге АКШ вәкиле Майкл Макфол белән дә күрешергә өлгерде.

• • • •

**20 СЕНТЯБРЬ КӨННЕ** КФУның икенче уку корпусында **ӨЙРӘНҮ ТРЕВОГАСЫ УЗДЫРЫЛДЫ**. Университетның янгынга каршы профилактика бүлегенең эчке режимын тәэмин итү һәм гражданнар оборонасы, хезмәт куркынычсызлыгын саклау Департаменты башлыгы Мөхәммәт Кәримуллин сүзләренчә, «коткарылганнар» саны – 1128 кеше булган һәм барлык эш-гамәлләр сигез минутлык нормативка тулысынча сыешып беткән.

• • • •

20-21 сентябрь көннәрендә Ярославль өлкәсенең Рыбинск районында **«ФУНДАМЕНТАЛЬ ТИКШЕРЕНҮЛӘР ҺӘМ ЮГАРЫ БЕЛЕМ» (BRHE) ПРОГРАММАСЫ БУЕНЧА ФӘННИ-МӘГАРИФ ҮЗӘКЛӘРЕ КОНФЕРЕНЦИЯСЕ УЗДЫ**. Биредә КФУдан Физика институты җитәкчесе А.В.Агафонов, квантлы электроника һәм радиоспектроскопия кафедрасы җитәкчесе, профессор М.С.Таһиров, физика институты хезмәткәре Ю.В.Малинина, шул ук иститутның аспиранты Р.Р.Газизуллин һәм А.М.Бутлеров исемендәге Химия институты аспиранты Ш.Ф.Галәлетдиновлар катнашты. Иң яхшылардан дип саналган 5 постер арасында чарада катнашкан ике аспирантыбызның да эше бар.

*kpfu.ru сайты материаллары файдаланылды.*






Руслан Гыйниятов, pravtatar.ru фотолары

# Шәрык - безнең дөнья!

**Алинә САДЫЙКОВА,**
хәбәрче

25 сентябрь көнне Уникс янында кара костюмнан булган кешеләрнең күплегенә аптырамадыгызмы? Әллә инде бөтенләй игътибар да итмәдегезме? Хәбәрдар булмаганнар өчен мәгълүмат: бу көнне Көнчыгышны өйрәнүчеләрнең Россиякүләм VIII җыены булып узды. Казан көнчыгышны өйрәнүчеләрне генә түгел, бу өлкәне үз итүчеләрне дә бер түбә астына җыйды.

Көнчыгышны өйрәнүчеләр җыены ике елга бер мәртәбә үткәрелә. Бу чараның Казанда уздырылуы да беренче түгел: башкалабыз галимнәрне 1999 елда үзендә бер җыйган инде. Тәүге тапкыр да җыелу урыны булып Казан юкка гына сайланмаган: «Казан көнчыгыш мәктәбе – көнчыгышны өйрәнүнең дөньякүләм символы! Минем фикеремчә, нәкъ менә Казанда бу юнәлешне үстерергә, дәвам иттерергә кирәк. Белүебезчә, Казан кыйтгаларның һәм мәдәниятләрнең кисешкән урыны. Көнчыгышны өйрәнү өчен иң кулай вариант ул – Казан», – дип билгеләп үтте кайчандыр университетыбызның тарих факультеты аспиранты булган Әкрам Калан.

Җыенның оештыручылары: Россия фәннәр академиясенең көнчыгыш телләр институты, Казан (Идел буе) федераль университеты, КФУның Көнчыгыш телләр һәм халыкара мөнәсәбәтләр институты, Россия фәннәр академиясенең көнчыгышны өйрәнү буенча Фәнни советы, Россиянең көнчыгышны өйрәнүчеләр җәмгыяте һәм Россия фәннәр академиясенең тарих-филология фәннәре бүлеге.

Чараны ТР Премьер-министры Илдар Халиков ачып җибәрде. Ул җыенда катнашучыларны Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов һәм ТР хөкүмәте исеменнән сәламләп, Президентның мөрәҗәгатен яңгыратты. Икенче булып сүз КФУ ректоры Илшат Гафуровка бирелде. Катнашучыларны сәламләгәннән соң, университетыбыз башлыгы килгән кунакларны кыскача гына Казан федераль университетының структурасы белән таныштырып узды. Җыенның үткәрелү урыны итеп Казанны сайлаганга рәхмәт сүзләре белдерде.

Россиянең көнчыгышны өйрәнүчеләр җәмгыяте президенты Виталий Наумкин тарафыннан ТР Дәүләт киңәшчесе Минтимер Шәймиевка әлеге җәмгыятьнең иң дәрәҗәле бүләге – Игнатий Крачковский медале тапшырылды. М.Шәймиев үзе килә алмау сәбәпле, бүләк Илдар Халиковка бирелде.

Шул ук көнне кичке сәгать алтыда җыен уңаеннан Сәнгать бүлеге студентлары бәйрәм концерты оештырып, килгән кунакларның күңелләрен ачты.

Чара өч тәүлек буе дәвам итәчәк. Анда КФУның алтмыштан артык галиме катнашыр дип көтелә. Җыенда сүз көнчыгышны өйрәтү мәсьәләләре, аның күпфакторлы тарихын, мәдәниятен, динен анализлау, шулай ук, халыкара мөнәсәбәтләр системасының кайбер аспектлары турында барачак.

## • Европа телләре көне


# Инглизчә дә яхшы бел...

**Динара ӘХМӘТОВА,**
хәбәрче

«Хола», «бонжорно», «добр дан», «норок»... Сөер яңгырый кебек. Бу телләрне бераз гына булса да белгән укучыларыбыз нәрсә турында сүз барганын яхшы аңлаганнардыр. 26 сентябрь – Европа телләре көне. Чарадан Казан федераль университетының Евроклубы да читтә калмады.

Әлеге датаны Европа советы Европа телләре елы вакытында – 2001 елның 6 декабрендә кабул итә. Максаты – мәктәптә, гомумән, яшәү дәверендә төрле телләрне өйрәтү. Соңгы елларда берничә чит тел белмәгән кешенең дәрәҗәсе юк дип әйтсәң дә дөрес булыр.

**Ахыры 2нче биттә.**




Әмир Фазлыйәхмәтов фотосы

• Европа телләре көне

# Инглизчә дә яхшы бел...

**Башы 1нче биттә.**

Югары уку йортына кергәндә дә, эшкә урнашканда да нинди чит тел белүеңне сорыйлар. Әлеге чара шулай ук мәдәни һәм телара мөнәсәбәтләрне ныгытырга, Европа телләренең ни дәрәҗәдә бай икәнен күрергә ярдәм итә.

Европа кыйтгасында 225 телнең өчтән-икесе бөтенләй юкка чыккан дигән мәгълүмат бар. ЮНЕСКО 2009 елда Россиядәге 136 телгә бетү куркынычы яный дип белдерде. Европаның иң киң кулланылышлы теле булган рус теле, билгеле, география ягыннан карасаң да, территориянең зурлыгы буенча да Европаның күпчелеген тәшкил итә. Якынча 150 млн кеше үз туган теле дип, рус телен саный икән. Икенче урындагы немец телендә 95 млн кеше аралаша. Француз, инглиз һәм итальян телләре 60 млн европалының туган теле булып тора. Испан, польша һәм украина телләре бераз калыша.

1980 елларга кадәр популярлыгы белән беренчелекне алып торган рус теленә карата кызыксыну бүген ул дәрәҗәдә зур түгел. Инглиз теленә булган ихтыяҗ көннән-көн үсә дияргә кирәк, шулай ук кытай, гарәп, төрек телләре дә соңгы елларда популярлык казанып килә.

Менә шундый кызыклы фактларны искә алып, уку йортыбызның Евроклубы актив эшчәнлек алып бара. Европа телләре көнендә студентлар өчен итальян, словения, испан, польша, немец телләре буенча дәресләр үткәрелде. Словения, Италия дәресләрендә әлеге ил вәкилләре дә катнашты. Клуб шәһәребезнең башка уку йортлары белән дә тыгыз элемтәдә тора. «Бу чараны үткәрергә уку йортыбызның төрле тел үзәкләре ярдәм итте. Шулай ук мәдәни кичәләр, чит ил уку йортлары белән онлайн семинарлар, «түгәрәк өстәл»ләр уздырабыз», – диде клуб администраторы Наталья Чернова.

Уку йортыбызда тәүге мәртәбә уздырылган Европа телләре көне үз нәтиҗәсен күрсәтер. Ансы вакыт эше... Иң мөһиме, бу көнне үткән дәресләрдә катнашучылар яңа чит тел өйрәнү өчен нигез булдырды.

• Шәхес

## Җәүдәт Сөләйман:

# «Безгә чикләр кирәк түгел»

**Рифат СӘЛАХ**

Татарстанда яшәп Җәүдәт абый турында ишетмәгән кеше сирәктер. Техник фәннәр докторы, КФУның теоретик кибернетика кафедрасы профессоры, Татарстан Фәннәр академиясенең вице-президенты, «Сәләт» проектлары җитәкчесе, шагыйрь... Николай Лобачевский исән булса үзе дә Җәүдәт абыйдан көнләшер иде, мөгаен. Халкыбызның талантлы балаларын бергә туплаган «Сәләт»не оештыруы гаҗәп түгел.



■ *Җәүдәт Сөләйманов туганнары, дуслары белән*

**– Сәләтле балалар һәрвакыт тәртипле буламы?**

– Юк. Сәләт белән тәрбия бер дә бәйләнмәгән. Без күнеккән инде, безнең тирәдәге белемгә омтылган балалар күп вакытта яхшылыкка тартыла. Мәктәптә дә, гаиләдә дә әхлаклы булу әйбәт дигәч, алар шундый булырга тырыша. Әмма әхлаклы булу мохиттән килә. Кайсыбер гаиләдә, ишегалдында идеология юк. Шуңа күрә хәзер белем белән әхлак бергә бәйләнмәгән. Бигрәк тә әгәр акылың булып, әхлагың булмаса, үсеп китәргә мөмкинлекләр дә күбрәк кебек. Әдәпле дә, акыллы да булу өчен үзенә бер рухи көч кирәк.

**– Сез чит илләрне күргән кеше буларак әйтегез әле. Сезнеңчә илләр арасында чикләр кирәкме?**

– Куяннар, төлкеләр, бүреләр бервакытта да чик белән яшәми бит. Әмма аларны син бер абзарга куеп кара, хәзер берсен-берсе ашап бетерәләр! Чикләр кирәк түгел, мин ул мохитне үз итмим. Ләкин технологияләр үсә барса да, кешенең рухы, кешелеклелеге кими. Безнең цивилизациягә бу чикләрне ачсаң, берничә ел эчендә Европада нәрсә калыр иде икән? Гомумән алганда, кешелек өчен акча белән чикләрнең ни өчен икәнлеге башыма сыймый.

**– Сезнең сакал шәрифләрегез турында да бер сорау бирим әле. Ни өчен үсә икән ул? Аны кырырга уйлаганыгыз юкмы? Бу сезнең өчен берәр билгеме?**

– Бу бернинди билге дә түгел. Студент чакта төзүчелек отрядларында йөри идек. Күбебез сакал калдыра. Ни хикмәт, сакалым яратып йөргән кызга ошады. Венера апаң (*Җәүдәт абыйның хатыны – Р.С.*) ничектер уңай кабул итүен тойдым. Ә миңа мәхәббәтем төшкән кызны ничектер үземә карату кирәк иде. Ул бер дә җиңел булмады. Сакаллы итеп үземне бүген дә күз алдына китермим әле... Авылда әти-әни аны бөтенләй кабул итмәделәр. Әти миңа: «И улым, хәзер кунаклар килә. Менә кайчы сиңа, әйдә тизрәк алдыр», – ди. Әтием гомер буе авылда тәртип урнаштырып, бер сантиметр озын чәч үссә дә, кеше балаларының чәчләрен кистертеп йөргән кеше. Кинәт кенә аның сакаллы малае кайткан. Зур бер катастрофа кебек кабул ителде ул: «И, бабаң кайткан, Шәүкәт», – дип аңардан көлә дә башладылар. Мин ике ут арасында калдым. Соңрак әтиемә сүз бирдем: «Кандидатлыкны яклыйм да сакалны кырам!» Якладым, кырдым. Җиде ел буена танышларым барсы да күнегеп беткәннәр икән. Нәтиҗәдә, кемнәрдер танымый. Исәнләшәм – дәшмиләр, аннары борылып та карамый башладылар. Өйдә балалар елый: «Безнең әти түгел», – дип. Шуннан соң тагын бер генә мәртәбә алдырдым – докторлык диссертациясен яклагач.

**– Җәүдәт абый, «Сәләт» кебек зур оешманы җитәкләп, ялыкмыйсызмы, шәхси тормышыгызга вакытыгыз каламы?**

– Минем ул гомуми тормышым да, шәхси тормышым да. «Сәләт» миңа көч бирә, үстерә. «Сәләт» мине нинди дер бер өлкәдә профессионал булырга мәҗбүр итә. Чөнки монда үзеңне нинди дер бер белгеч, үз эшеңнең остасы итеп күрсәтә алмасаң, сиңа хөрмәт булмаячак. Бер кеше беркайчан да бөтен өлкәдә дә зур профессионал була алмый. Кемдер әйбәт бии, кемдер математиканы яхшы белә, кемдер шигырь яза. Син үз өлкәңдә башкаларга киңәш бирер дәрәҗәдә белгеч булырга тиеш. Шул очракта гына син кызыклы! Беренчедән, «Сәләт» ардырмый, мин аны югарыдан бирелгән бер вазифа итеп кабул итәм, шуннан рәхәтлек алам. Икенчедән, әйткәнемчә, ул үземә ачылырга, сәләтемне ачарга ярдәм итә торган даирә.

• Бездә кунак бар

# Коръән ул - океан

**Сөләйман НӘҖМИЕВ**

Кичә КФУның Филология һәм сәнгать институтында А.М.Горький исемендәге дөнья әдәбияты институты директоры, Россия Фәннәр Академиясе академигы Александр Куделин бертөркем галимнәр, аспирантлар һәм студентларга лекция укыды.




Очрашуны Филология һәм сәнгать институты директоры, профессор Рәдиф Җамалетдинов ачып җибәрде һәм галим белән мондый очрашу югары уку йорты тарихына аерым бер сәхифә булып кереп калачагын белдерде. Александр Куделин (*рәсемдә*) чыгышында сүз, нигездә, гарәп илләре әдәбияты тарихы, аның төрле этаплары, шушы өлкәдә тикшеренүләр алып барган белгечләрнең хезмәтләре, гарәп каллиграфиясе үзенчәлекләре хакында барды. Ул үзе гомер буе гарәп илләре әдәбияты тарихын, әдәбият теориясен һәм чагыштырма әдәбият белемен өйрәнгән дөнья күләмендә мәшһүр галим. А.Б.Куделин урта гасырлардан алып хәзерге көнгәчә булган әдәби-эстетик караш һәм әдәби үзара бәйләнеш проблемалары белән кызыксына, аның нечкәлекләрен фәнни яктан ача, Көнчыгыш әдәбияты тарихы буенча тикшеренүләр алып бара.

Филология һәм сәнгать институтында узган бүгенге очрашуда да ул гарәп поэтик кануннарына хас сыйфатлар турында үз фикер-карашлары белән уртаклашты. Ә инде исламдагы изге китап хакындагы сорауларга җавап биргән вакытта Александр Куделин, Коръәнне океанга тиңләде һәм аның эчтәлеген ачар, тәрҗемә итәр өчен Коръән белән гомер буе шөгыльләнергә кирәк диде.

# Германиядә уку бушлай!

**Зилә ФӘСХИЕВА,**
хәбәрче

26 сентябрь көнне Педагогика һәм психология институтында Германиядәге Лейпциг университеты фәнни-хезмәткәре Андреас Мәдебах белән очрашу үтте.



Ул Германиядәге укыту системасы, психология өлкәсендәге кайбер оештыру моментлары, студентлар тормышы турында сөйләде. Бирелгән бер генә сорау да җавапсыз калмады.

Заманында Гёте белем алган Лейпциг университетына 1409 елда нигез салына. Бүгенге көндә 14 факультет үз эченә алган уку йорты Германиядә иң көчлеләр исемлегендә. Европаның иң абруйлы югары уку йортында бакалавр дәрәҗәсе алыр өчен 6 семестр, ә магистрлыкка 4 семестр укырга кирәк икән. Иң кызыгы шул: уку дәверендә сиңа үз белгечлегеңнән башка бернинди фән дә укытылмый. Кунагыбыз мисал итеп психология факультетын китерде. Димәк, Лейпциг университетында психолог белгечлеген алып чыгыйм дисәң, барлыгы 10 семестр дәвамында бары тик психология фәнен генә укыячаксың. Кызык өчен: психологиягә кереш; гомуми, биологик, эксперименталь үсеш, социаль хезмәт, клиник психология һәм тагын әллә нинди психологияләр кирә икән анда!!! Уку йортын тәмамлаганда, шул өлкәгә караган фәнни хезмәт язарга кирәк. Ә башка фәннәрне укымыйлармыни дигән сорауга җавап бик гади. Алар барсын да мәктәптә укыйлар! Философия, политология, анатомия һәм башка шуның ише гомуми мәгълүмат алырга кирәк булган фәннәр мәктәп курсында ук үтелә.



Алия Галимуллина фотосы

«Студентлар моны аңлый, шуңа да бу мәктәп түгел, квалификацияле белгечләр әзерли торган югары уку йорты», – диде Андреас Мәдебах. Германиядәге укыту системасының тагын бер үзенчәлеге бар. Бездә билгеле бер фән буенча курслар тәмамлангач, семестр ахырында имтихан бирәбез. Шуның белән ул дәресләр бетә. Аларда исә башкачарак: имтихан шул семестрдан соң түгел, ә тагын бер семестр үткәннән соң бирелә икән. Бу процессны студентларның бе+лемнәре тиз генә онытылмасын, авырып йә башка сәбәп белән дәрес калдыручылар материалны үзләштереп бетерергә өлгерсен өчен эшләнә дип аңлатты алман галиме. Белем алу бушлай, ләкин һәр семестр саен мәҗбүри түләүләр башкарырга кирәк. Ул – бер семестрга 100 евро күләмендә. Акчалар студентларның үзләренә үк тотыла: аларга уку елы дәвамында юлда бушка йөрер өчен транспорт билетлары ясап бирәләр. Тулай торакта урын һәркемгә дә җитә, хәтта буш урыннар да күп, чөнки студентлар фатирлар алып тора.

Чит илләрдән килеп укучылар да монда бихисап (заманында безнең Россиядән язучы Николай Радищев һәм химик Александр Базаров та шунда белем алган, З.Ф.), чөнки Лейпциг университеты дипломы белән дөньяның теләсә-кайсы почмагында эшкә урнашырга мөмкин. «Ә психологлар сездә эш табамы? Безнең шәһәрдә алар кирәгеннән артык күп һәм күбесе эшсез», – дигән сорауга, Андреас Мәдебах: «Эшсезлек белән безнең илдә проблема юк. Укып чыккан һәркемгә эш бар. Психотерапевтларга хөрмәт бик зур», – дип җавап бирде.


Очрашу тәмам... Сорауларга да җавап алынды кебек. Ләкин бездәге һәм көнбатыштагы укыту системасы арасында аерма шактый. Димәк, белем бирү системасы турында уйланырга да җирлек бар...

● Киңәш-табыш

# Үз-үзеңне укырга мәҗбүр итеп буламы?

**Зилә ФӘСХИЕВА,**
хәбәрче

Барыбыз да яхшы беләбез: уку җиңел эш түгел. Мәктәптә укыганда әти-әниләр, укытучылар контроле астында буласың, теләсәң дә, теләмәсәң дә укырга туры килә. Ә менә студент булгач...



Һәркөнне студентка уку йортына барып, сәгать ярым лекцияләрдә утырырга, барысын да истә калдырырга, бөтен аудитория алдында җавап бирергә, язып барырга һәм тагын әллә ниләр эшләргә кирәк. Әле ул гына түгел, өйгә кайткач, тынычлап ял итәргә уйласаң, ашарга пешерелмәгәнлеге, иртәгә нинди фәннән контроль бирем булачагы, өй эшләрен әзерләргә кирәклеге ачыклана. Шуңа күрә ни генә дисәгез дә, уку - ул энә белән кое казу дип белми әйтмәгән борынгыларыбыз. Менә шушы бөтенесенең берьюлы өелүе университет, техникумнарда укучы студентларны дәресләрдән качарга, парларны ешрак тозларга мәҗбүр итә. Укучы әкренләп иреккә чыга, үз-үзе белән идарә итә алмый башлый. Шуңа күрә бик күпләр тормыш баскычы буйлап өскә түгел, ә киресенчә, аска тәгәрәргә мөмкин. Бу вакытта сорау туа: «Ә ничек итеп үзеңне укырга мәҗбүр итәргә?» Хәзер шушы сорауга җавап эзләп карыйк...

Беренчедән, алдыгызга максатны дөрес итеп куярга өйрәнегез. Бу семестрны «биш»ле һәм «дүрт»леләргә ябу өчен, мин нәрсәләр эшләргә тиеш, дигән сорауга җавапны язып ук куйсагыз да комачауламас.

Вакытыгызны дөрес бүләргә өйрәнсәгез, бик күп проблемалар үзеннән-үзе юкка чыгар. Билгеле бер режим булдыру да файдага гына. Бик әһәмиятле булмаган эшләрне калдырып, дәресләрегезне карау үз нәтиҗәсен бирер. Шул ук вакытта ашауны да онытмаска кирәк. Кич белән иренмичә урамда әз генә йөреп керү баш миенең эшчәнлеген яхшыртып җибәрә. Әлбәттә, йокы вакытын компьютер артында мәгънәсез аралашуларга әрәм итмәскә тырышыгыз.

Ихтыяр көчегезне булдырырга өйрәнегез. Сүз дә юк, шундый чаклар була: килеп сугып, кычкырып кит, әмма кешене берничек тә эшләргә мәҗбүр итеп булмый. Мондый очракта, ихтыяр көченең нинди дәрәҗәдә булуы бик әһәмиятле. Тешләрегезне кысып, йодрыгыгызны җыеп, теләгәнгә түгел, ә кирәккә эшлим, дип дәресләрегезне әзерләргә утырыгыз. Мондый тәҗрибә укуда гына түгел, киләчәк тормышта да һәрвакыт ярдәм итәчәк!

Дәрескә әзерләнү урыныгыз уңайлы, үзегезгә ошаганча булсын. Йоклый торган диванда гына нидер язгалап, сызгалап ату зур нәтиҗә бирмәячәк, билгеле. Яхшылап өстәл артында утырып, язасын язып, укыйсын укып бетерергә киңәш ителә. Дәрес әзерләгән вакытта, «Вконтакте», «Skype» ише интернет ресурсларының ачык булуы да баш миенә нык комачаулый.

Күңелсез лекцияләрне кызыклырак итү өчен, дәфтәрдә язылганнарны фломастер йә төсле ручкалар белән бизәп барырга була. Беренчедән, кирәкле цитаталарны истә калдыруы җиңел, икенчедән, йокы турындагы уйлар да тиз арада эреп юкка чыгачак.

Әле шунысы да бар: өйгә бирелгән эшләрне студентлар, гадәттә, соңгы мизгелгә кадәр сузарга ярата. Эшне тәмамлауга караганда, башлавы күпкә катлаулырак. Моның сәбәбе гап-гади: ялкаулыкның сезне җиңүе. Никадәр тизрәк башласагыз, укуда үзгәрешләр шулкадәр тизрәк үзен сиздерәчәк.

Гадәттә, укытучылар дәресләрен биш–ун минутка иртәрәк бетерә. Шул вакытта өйгә бирелгән эшләрне карарга була.

Тагын шунысын онытмагыз: бары белемле булганда гына сез кемгәдер кирәк һәм тормышта үз юлыгызны табарга мөмкинлекләр дә бар. Димәк, бар көчне җыеп, тырышып укырга, укырга һәм тагын бер кат укырга!

● Әдәп-әхлак

# Тәкәбберлек кешене бизәми!

**Гөлсем АБДУЛЛИНА,**
хәбәрче

Әйләнә-тирәгә күз салсак, әллә нинди холыклы кешеләрне очратырга мөмкин. Кемнәрдер сабыр, икенчеләре ялган сөйләргә ярата, ә кайберәүләрдә көнчелек чиктән ашкан. Араларында тагын бер төркем кешеләр бар. Болар – тәкәббер кешеләр. Сүзлектә бу сүзгә «үзен өстен күрүчеләр, башкаларга түбәнсетеп караучылар» диелгән. Дөрестән дә, гап-гади мәктәп балаларында, студентларда, олы абый-апаларда да бу сыйфатны күрергә мөмкин. Кемнеңдер күлмәге яңарак, кемнеңдер әтисенең машинасы бик кәттә... Гаиләдә тәрбия ничек салынса, аның җимешләрен балада күрәбез – бусы хак сүз. Кешенең кешегә мөнәсәбәте дә әти-әни тәрбиясеннән килә. Тәкәбберлек ислам динендә хәрам гамәл, чөнки Аллаһ барыбызны да бертигез итеп яраткан. Пәйгамбәребез бер хәдисендә болай ди: «Тәкәбберләнгән кешене Аллаһ түбән төшерер. Ихлас күңелле кешенең исә дәрәҗәсен күтәрер».

Кайчакта төрле җәмәгать урыннарында эшләүче кешеләр килгән клиентларга кигән киеменә карап бәя бирә. Шуңа күрә дорфа, әдәпсез генә сөйләшә. Еш кына байлыгы, нәселе, дәрәҗәсе, белеме белән мактанучы тәкәбберләрне күрергә мөмкин. Бигрәк тә җитәкчең таләпчәнлек сыйфатын тәкәбберлек белән бутаса, аның кул астында булган кешеләргә кыенга туры килә. Шул ук вакытта миңа тәкәббер кеше димәсеннәр, ихлас күңелле кеше дисеннәр, дип, һәрнәрсәгә риза булу да дөрес түгел. Мөселман кеше һәр нәрсәнең урталыгында булырга тиеш. Гүзәл әхлак сыйфатлары һәм әдәп кенә кешене бизи ала. Кешеләр арасында булган җылы, дустанә мөнәсәбәтләргә ни җитә!

● «Әллүки» тәрәзәсе

# Кактус кайчан чәчәк ата...

**Ильмира КАМАЕВА,**
татар филологиясе бүлеге студенты

Кактусның «Әллүки»гә нинди катнашы бар соң дияр укучылар. Бар шул... Чөнки утырышка килгән кунакларның берсе нәкъ менә татар яшьләре арасында рэп остасы буларак билгеле Илназ Кактус иде.

Филология һәм сәнгать институтының «Әллүки» әдәби-иҗат берләшмәсендә кем генә кунак булмаган да, нинди генә танылган шәхес аның кунаклар дәфтәренә теләк язмаган икән?! 19 нчы сентябрь көнне узган чираттагы утырыш та гадәттәгечә кунакларга бай иде.

Илназ яшь каләм ияләренә үзенең иҗаты, кызыксынулары турында сөйләде. «Әллүки»челәрне исә рэп иҗат итү серләре, клип төшерү мәшәкатьләре кызыксындырды. Кактус үз гомерендә бары бер генә шигырь иҗат итүен һәм әлеге өлкәне үзенеке дип тапмавын да яшермәде. Татар рэп музыкасын үстерәсе килеп бу юнәлештә эшли башлый ул. Моннан өч ел элек «L.I.B.E.R.T.A.S» (латин теленнән «азатлык») исеме астында оешып иҗат иткән төркемнән Илназ бүген аерым җырлауга күчкән.

«Әллүки»челәрнең «Кактус кайчан чәчәк ата?» соравына Илназ: «Әле җәй көне генә чәчәк аттым», - дип бик тапкыр җавап кайтарды. Иң кызыклысы шул: Кактус киләчәктә дә «Әллүки» утырышларына йөрергә һәм рэп серләре белән уртаклашырга вәгъдә бирде.

Утырышның тагын бер үзенчәлекле кунагы, үзебезнең бүлекне тәмамлаган, бүгенге көндә «Идел» журналында эшләүче яшь шагыйрә Эльвира Һадиева иде. Эльвираны да «Әллүки»челәр сорауларга күмде. Шагыйрә яшь дусларына иҗади биремен калдырырга да онытмады. Берләшмәгә йөрүче студентлар уен рәвешендә хикәя язу өчен кызыклы идеяләр белән уртаклашты. Димәк, киләсе утырышларда без инде яңа гына табадан төшкән әсәрләребезгә анализ да ясаячакбыз.

Әгәр син дә әдәби әсәрләр иҗат итәсең яки, гомумән, иҗатка гашыйк кеше икәнсең, «Әллүки» сине һәр атнаның чәршәмбесендә Филология һәм сәнгать институты бинасының 103 аудиториясендә үзенең утырышларына көтеп кала. Бездә күңелле, син дә кушыл!



Руфинә Габдрахманова фотосы

● Сакаллы сабый

# Ямьле балачак иле...

**Алмаз МАНСУРОВ,**
татар филологиясе бүлеге студенты

Бүген мин бөтенләй чит-ят, үзгә дөньяга эләктем. Урам буйлап салмак кына атлап барган уңайга, әкият белән чынбарлык чиген уздым, ямьле балачак иленә аяк бастым.



Тирә-ягымда тылсымчыларны, фәрештәләрне күреп гаҗәпләнмәдем мин. Киресенчә, гадәти бер күренеш итеп кабул иткәнгәме, аларның йөзләреннән бөркелгән нур иреннәремә кунды, йөрәгемә ниндидер ләззәтле бер хис үтеп керде.

Яраттылар, үз иттеләр алар мине. Мәйданчык янындагы эскәмиягә барып утыруым булды, аягыма туп килеп бәрелде. Аны кулларыма алдым. Нишләтим икән дигәндәй, әйләндергәләргә тотындым. Шундый мавыгып киткәнмен, күрми дә торам икән. Тупның хуҗасы табылган бит. Менә, янымда бер нәни генә фәрештә басып тора. Үзе оялып башын игән. Мин уенчыкны сабыйга суздым:

– Мә, ал, үскәнем!

Сөеп аркасына кагылып кына калдым, бәләкәч тубына тибә-тибә йөгереп китте.

Әнә, атынгычлар янында ике канатлы фәрештә – бер кызчык уйнап йөри. Ике канатлы диюем шуңа, аның янында әтисе дә, әнисе дә бар. Шуларның кулларына ябышып уйнаклый ул.

Ямьле балачак иленең балалар уен мәйданчыгы икәнен хәзер барыгыз да аңлагансыздыр инде. Әти-әниләрнең тылсымчы икәнен, фәрештәләрнең балалар булганын да чамалыйсыздыр. Кызык бит, әйеме?

Кызык кына түгел, сокландыргыч матур да әле. Менә бер ана балалар арбасы өстенә иелеп, нарасые белән сөйләшә. Ә бәләкәч шундый сөенә ки, кечкенә генә аякларын, нәни генә кулларын селкетеп, көлә-көлә куана. Әнә теге малай әнисен ничек кысып кочаклый. Кечкенә генә куллары белән битеннән сыйпый, чәчләре белән уйный.

Ә мин шул балалардан көнләшеп утырам. Бик теләсәм дә андый ук ихлас була алмам кебек тоела. Ә шулай да, ниндидер бер өмет белән өйгә ашыгам.

Менә әнием. Мин бераз гына читенсенеп, аның янына барам. Куркып кына күзләренә багам. Әнинең миңа яратып каравын күреп, кыюланып китәм, аны кочаклап алам.

Ул да мине кочаклый. Тик... Үскәнмен инде. Әни кочагына сыймый да башлаганмын. Шуңа карамастан аның назын тоям, мәхәббәтен сизәм... Тагын ни кирәк? Бәхет шушы түгелме?!

...Әле бер нәрсә турында уйлап куйдым. Үземнең дә тылсымчыга әйләнер вакытым җитеп килә түгелме. Киләчәктә мин дә кечкенә генә фәрештәләргә могҗиза тудырыр, аларны сөендерер өчен яшәрменме икән?

Ямьле балачак илен беребез дә онытмый. Онытырлык та түгел. Бала вакытыңда да, әти яки әни булгач та, оныкларың белән дә вакытыңны шунда уздырасы бит.

● Әдәби Ат

## Гүзәллек

**Алсу НУРГАТИНА**
Журналистика һәм социология факультеты студенты

*Урамымда төн карасы күптән,*
*Яңгыр явып үткән яңа гына.*
*Усал җилләр зифа ак каенның*
*Уңлап-суңлап кыйный яңагына.*

*Җылылыкны никтер сөйми*
*күзләр,*
*Салкын гына итеп елмая.*
*Җилләр булып яфракларны коя*
*Якты төскә буяп куйган да...*

*Матур булып була микән әллә*
*Салкын караш ташлап дөньяга?!*
*Күңел һәрчак матур диләр иде,*
*Йөрәгеңдә җылы булганда...*

*Ник алайса матур икән көзләр,*
*Күптән туңган көзнең хисләре.*
*Ә ул гүзәл,*
*Алтын яфрак ява,*
*Моңнар ява,*
*Исең китмәле!...*

*Өйрәт мине салкын йөрәк белән*
*Яратырга якты дөньяны.*
*Көч бир миңа кабат яктырырга*
*Онытып бар начар уйларны.*

*Ә көз матур,*
*Салкын йөрәк анда,*
*Эзләренә иңгән сарылык.*
*...Моңсулыкны юар тиздән*
*кышлар,*
*Сарылыр да җиргә кар булып...*

## Көз

**Булат ИБРАҺИМ**
Татар филологиясе бүлеге студенты

*Сине сагынып бәлкем яңгыр явар*
*Аяз күкне чәлпәрәмә ватып.*
*Бу яңгырлар карга әверелгәч,*
*Син кайтырсың кебек...*
*Тик кайтып*
*Салкын карлар барыбер кайнар булмас,*
*Боз сөңгесе купмас йөрәктән.*
*Җәйләр буе сайрар кошларны да*
*Сары яфрак куа тирәктән...*

*Әйдә китсен җанда калган җылы*
*Һәм шартласын хисләр диңгезе.*
*Ул диңгездә энҗе бөртегенең*
*Булганлыгын беләм тик үзем.*

*Минем күзем хәзер чит тәрәздән*
*Чит бер күккә зәңгәрлеген түгә.*
*Тәннән чыгып киткән соңгы җанның*
*Кайтканы юк... кайтмый икән нигә?..*
*Салкын урамнарның юлларында*
*Җил исергән дусты төн белән,*
*Таңнар атар тиздән,*
*Таңнар атар,*
*Кояш чыгар күккә, мин беләм...*

*Ә әлегә күктә кое болыт,*
*Ә артында аның салкын ай.*
*Сары ай да артык сары булып,*
*Кайгыларга баткан, мескенкәй.*
*Әй, ай дустым, әйдә, ярыл әле,*
*Тын диңгезгә сикер,йә Һиндка.*
*Су астында калсын гөнаһлы җир,*
*Су астында калсын, тынлыкта...*

*Ә әлегә күктә кое болыт,*
*Сине сагынып шашкын яңгыр ява.*
*Туңган юлны чәлпәрәмә ватып*
*Соңгы җаным булып тамчы тама.*

## Көзге элегия

**Гөлчирә ИМАНКОЛОВА**
Татар филологиясе бүлеге студенты

*Күрәсеңме, агачларга өр-яңадан*
*Алтын сыман сары бәс сарган.*
*Кайберләре тоеп шәфәкъ алсулыгын*
*Оялудан ахры кызарган.*

*Көз хөкеме чыккан диеп табигатьтә,*
*Юк, теләми күңел тынарга.*
*Ул күнеккән ярсуланып һәрчак,*
*Язгы ташкын кебек җырларга.*

*Күнгән инде синең кайнарлыкка,*
*Очкын сипкән кара күзләргә...*
*Инде беләм,бу карашым*
*бер дә юкка*
*Әзер сине көн дә эзләргә.*

*Син, зинһар, дим берүк ачуланма*
*миңа*
*Өмет өзмим килер язлардан.*
*Тик бер сүзең җитә миңа юанырга*
*Син күзләрдә биргән назлардан...*

**Руфинә ГАБДРАХМАНОВА**
Татар филологиясе бүлеге студенты

***

*Көз төсенә кердем кебек:*
*Мин – сары...*
*Тирги хисләремне яфрак сыннары.*

*Офык кояшны йоттымы – караңгы...*
*Җиргә төшкән сарылыкның бар аңы!*

*Көз исемә төште сыман –*
*Тилерәм.*
*Язларыма кайттым җәяү...*
*...Киредән...*

● Спорт



## Зур исәп вә зур хезмәт

**Рифат СӘЛАХ**

Казан «Ак Барс»ы Континенталь хоккей лигасының гомуми турнир таблицасында беренче урында бара. 24 сентябрь көнне үз бозында Екатеринбург «Автомобилист»ын җиңгәннән соң да казанлылар бу үрне саклап калды.

Матч «барслар»ның өстенлеге белән башланып китсә дә, беренче периодта исәп ачылмады. Автомобильчеләрнең бер генә дә Казаннан очкосыз китәсе килмәде. Шуңа да ураллылар саклануга аерым игътибар бирде. Казанлылар уенны күпме генә каршы якта үткәрергә тырышмасын, нәтиҗәсе булмады. Бәхеткә, кунаклар контрһөҗүмнәрдән файда алмады.


Икенче периодта мәйдан хуҗаларының гол кертү теләге тагын да көчәйде. Шулай да озак көтелгән беренче алка бөтенләй көтелмәгәнчә керде. Узган ел гына Екатеринбург данын яклаган казанлы Денис Абдуллин матчның 23 нче минутында беренче карашка гади генә сукты. Ни хикмәт, әллә нинди катлаулы алкаларны тотып калган кунаклар капкачысы Кристофер Холт бу юлы бераз ялгышты. «Ак Барс» алга чыкты – 1:0. 29 нчы минутта Янне Песонен исәпне 2:0гә, 34 нче минутта Денис Абдуллин 3:0гә төзәтте. Матчның өчтән икесе казанлылар файдасына өч тапкырга өстенлек белән тәмамланды.

Өченче период башында «барслар» исәпнең зурлыгына өметләнепме, әллә нигә уңышсыз башлады. Нәтиҗәдә, 48 нче минутта Растислав Шпирко яшь капкачыбыз Эмиль Гариповны бирелергә мәҗбүр итте. Исәп 3:1. 55нче минутта казанлылар дүрт уенчыга гына калуга карамастан исәпне 4:1гә үзгәртүгә иреште. Кирилл Петров пасыннан соң, Алексей Терещенко алканы капкага шудырды. 58 нче минутта Илья Никулин, 59 нчы минутта Нико Капанен гол кертеп, «Ак Барс»ка 6:1 исәбе белән җиңү китерде.

Кичә «барслар» гамәлдәге чемпион Мәскәү «Динамо»сы белән очрашты. Газета тапшырылганда матч әле башланмаган иде.

● Ял сәгате

**Рифат СӘЛАХ, Динара ӘХМӘТОВА** бергәләп төзеде.




! Алдагы санда чыккан сканвордның дөрес җавапларын иң беренче булып җибәргән Зөһрә Шакированы котлыйбыз. Бүләкне безнең редакциядән килеп алырга мөмкин. Сездән сканвордка җаваплар көтеп калабыз!

● Кети-мети

*Имтиханда:*

*- Ат көче нәрсә ул? – дип сорый остаз.*

*- Ул буе бер метр һәм авырлыгы бер килограмм булган атның көче, - дип җавап бирә студент.*

*- Андый атны сезнең кайда күргәнегез бар?*

*- Ә аны болай гына күреп булмый. Ул Париждагы үлчәүләр палатасында саклана.*

***

*Тарих укытучысы укучыга сорау бирә:*

*- Марат, әйт әле, Берлинны кем алган?*

*- Абый, мин алмадым!*

*- Ярый алайса, иртәгә әтиең белән килерсең.*

*Икенче көнне Маратның әтисе килеп җитә. Мөгаллим:*

*- Менә кичә улыгыздан: «Берлинны кем алган?» - дип сорадым. Ә ул «Мин алмадым»,- ди.*

*Әтисе улына карый да:*

*- Улым, алган булсаң бир!*

*Аптыраган укытучы боларны директор янына алып китә дә хәлне сөйләп бирә. Директор уйланып торганнан соң:*

*- Мин аларның нәселләрен беләм. Алар алмаган булырга тиеш!*

***

*Ике күрше сөйләшә:*

*- Ни өчен синең өеңдә көн дә мәче кычкыра?*

*- Мин аны юам.*

*- Мин дә юам. Минеке кычкырмый бит.*

*- Син аны сыкмыйсыңдыр.*

кара
UNIVERSMOTRI.RU

DARELFӨNYN УНИВЕРСИТЕТ
Тираж 1000
Газета бушлай таратыла

Баш мөхәррир - Илдар Азат улы Кәримов
Мөхәррир - Рифат Гали улы Сәлахов
Иҗат коллективы: Д.Р.Әхмәтова, А.Ю.Садыйкова, З.Ф.Фәсхиева
Биткә салу һәм дизайн буенча белгеч - Г.З.Камалиева

Газетаны гамәлгә куючы – Казан (Идел буе) федераль университеты
Редакция һәм нәшрият адресы: 420021, Казан ш., Профессор Нужин ур., 1/37 йорт, 318 каб.
Хәбәрләшү өчен телефон: 233-70-04.
Электрон почта: darelfonyn@mail.ru Сайт: kpfu.ru

Газета Федераль элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсендә 2012 елның 13 мартында ПИ № ТУ 16-00696 нчы таныклык белән теркәлде.
Бастырылуга кул кую вакыты: график буенча – 16.00, кул куелды – 16.00
«Карти» ҖЧҖ типографиясендә басылды, Казан ш., Восстание ур., 60 й.